ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.08.2019 ел Баулы шәһәре № 243

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 23 сентябрендә кабул ителгән «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында»гы 228нче карарына өстәмә кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының гаиләнең җан башына уртача керемен бәйле рәвештә, ата-ана түләвенә өстәмә компенсация билгеләү турындагы 2019 елның 12 августындагы №03-16/6427 хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

карар итә:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 23 сентябрендә кабул ителгән «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында»гы 228нче карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсацион түләүләр бирү тәртибендә:

1нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә, 1.6 пунктта таблицага түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Яшәү минимумыннан түбәнрәк (күп балалы гаиләләр өчен) | 0 | 0 | 0». |

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров